# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2026 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлегенең Малаевка торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

**2025 елның 19 ноябре** **№3**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Уставының 26 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Малаевка торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Малаевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Карамалы ав., Үзәк ур., 4 й.
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай ур., 16 йорт, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында гражданнарны кабул иткән көннән алып 10 (ун) көн эчендә урнаштырырга.

Кама Тамагы муниципаль районының
Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы ,
гражданнар җыенында рәислек итүче Э. М.Мөхәммәтшин